ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧӘЧӘКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

08.10.2019ел N 102

Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә
җирле әһәмияттәге мәсьәләләр
вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, ТР Спас муниципаль район Советының «шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында " гы 07.10.2019 ел, № 42-4 карары нигезендә», Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлеге Советы карары белән «Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм ТР Спас муниципаль районы җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында " 2019 елның 16 июлендәге 95 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлеге Советы карары

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан РеспубликасыСпас муниципаль районынының шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итәргә:

- җирлекнең генераль планына үзгәрешләр кертү һәм раслау;;

- Җирбиләмәләреннәнфайдалануһәмҗирлектөзелешекагыйдәләренәүзгәрешләркертүһәмраслау;;

- җирлекнең шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча җирле нормативларына үзгәрешләр кертү һәм раслау.

2. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авылҗирлеге башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән тапшыру турында килешү төзүне тәэмин итәргә

3. Әлеге карарны Спас муниципаль районының http:// www. spasskiy.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) закон белән билгеләнгән срокта бастырып чыгарырга.

Чәчәкле авыл җирлеге башлыгы: Ә.Н. Исмәгыйлева.